| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.02.2021 № 106

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 23 августындагы 840 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

РФ Юстиция министрлыгының 2017 елның 23 июнендәге 2754 номерлы боерыгы белән 2021 елның 17 гыйнварыннан норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүгә вәкаләтле бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнгән Р. М. Гибатдиновның бәяләмәсе нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Мактау грамотасы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Рәхмәт хаты турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 23 августындагы 840 номерлы карарының 1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3. Мактау грамотасы белән бүләкләү тиешле үтенечнамә кергән көннән алып биш эш көне эчендә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе белән рәсмиләштерелә. Мактау грамотасы белән бүләкләү биш эш көне дәвамында башкарыла.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7. Мактау грамотасы А 4 китап форматындагы кәгазь битеннән гыйбарәт. Мактау грамотасында бүләкләнүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) күрсәтелә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсенең кыскача тексты аның имзасы куела.».

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Хәмзин